**СОВЕТ ГАБИШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422606 с. Габишево,
пр. Молодежный, д.1
тел:   4-46-57

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ГАБИШЕВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422606 Габишев авылы,
Яшьләр урамы, 1 нчы йорт,
тел:   4-46-57

---

2025 елның 31 гыйнвар                                        171 номер

КАРАР

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2024елның 18 октябрендәге 145 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Габишев авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2024 елның 18 октябрендәге 145 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2 пунктның 1 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- гараж һәм машина урыннары, шул исәптән әлеге пунктның 5 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан урыннар;»

1 пунктның 1 пунктындагы дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Габишев авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Габишев авыл җирлеге Советының план-бюджет һәм икътисадый үсеш комиссиясенә йөкләргә.

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Габишев
авыл  җирлеге Советы рәисе                                        М.Ф.Миндубаев